**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең Отрада авылында гражданнар җыены карары**

24.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең Отрада авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Мөкерле авыл җирлегенең Отрада авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Отрада авылында чишмәне төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Мөкерле авыл җирлегенең Отрада авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мөкерле авыл җирлеге башлыгы _________ С.Н. Тюплина

Гражданнар җыены секретаре _________ Т.Н. Орлова